СОВЕТ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ

---

**РЕШЕНИЕ**
**14.11.2016**

Зеленодольск
шәһәре

**КАРАР**
**№ 147**

Зеленодольск муниципаль районы 2016 елның тугыз аена бюджет үтәлеше турында

«Зеленодольск муниципаль районы финанс – бюджет палатасы» муниципаль учреждениесе җитәкчесе О. П. Дёгтеваның Зеленодольск муниципаль районы 2016 елның тугыз аена бюджет үтәлеше турында мәгълүматын тыңлап фикер алышканнан соң, Россия Федерациясе Бюджет кодексына, 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законга, Татарстан Республикасы «Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставына, Зеленодольск муниципаль районында бюджет процессы турындагы Нигезләмәгә таянып, Зеленодольск муниципаль районы Советы **карар кылды:**

1. Зеленодольск муниципаль районы бюджетының 2016 елның тугыз аена үтәлеше турындагы мәгълүматны игътибарга алырга (кушымтада бирелә).

2. Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетына:

2.1. керемнәр һәм чыгымнар буенча Зеленодольск муниципаль районы бюджеты үтәлешен даими мониторинглауны алып барырга, төгәлләштерелгән план күрсәткечләрен үтәмәү сәбәпләрен анализларга;

2.2. үз керемнәрен арттыру буенча ведомствоара комиссия эшен активлаштырырга;

2.3. салым һәм салым булмаган түләүләр буенча түләп бетерелмәгән салымны кыскарту буенча барлык кирәкле чараларны күрергә, дәгъва-иск эшләрен башкаруны көчәйтергә;

2.4. 2016 елның 1 декабренә кадәр Зеленодольск муниципаль районы Башлыгы 2016 елның 08 февралендәге 01-03-32 номерлы карары белән расланган 2016 елда Зеленодольск муниципаль районы берләштерелгән бюджетының керем базасын арттыруга юнәлдерелгән чаралар планының үтәлеше буенча мәгълүматны Зеленодольск муниципаль районы Советына җибәрергә.

3.Зеленодольск муниципаль районы Советының социаль-икътисадый үсеш, бюджет - финанс мәсьәләләре, муниципаль милек һәм эшмәкәрлекне үстерү буенча даими комиссиясе үз утырышларында Зеленодольск муниципаль районы бюджетын үтәлеше мәсьәләсе буенча ай саен Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты утырышларында тыңларга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында Зеленодольск муниципаль районының мәгълүмат сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) Интернет челтәрендә урнаштырырга.

**Зеленодольск муниципаль районы Башлыгы,**
**Совет рәисе** **А. В. Тыгин**